

Ләмберә районы Чирмеш авылы читендә мавыктыргыч мотоузышлар уздырыла башлады. «Саранская гоночная команда» мотоцикл клубы, Ләмберә районы администрациясе ярдәме белән, Ватанны саклаучылар коненә багышланган «Кышкы Кузямбай – 2025» мотоспорт ярышлары уздырды.
Кузямбай - чирмешлеләр очен vзен-чәлекле урын. Борынгы риваятьләрдә шул авылнын карт бае нәкъ шул урман аланында яшь хатынын яшереп тотканы һәм биредә хәзинәләр, серле табышлар булуы турында әйтелә.

«Саранская гоночная команда» мотоцикл клубы вәкиле Александр Медведев бу атамада урын белән тирән бәйләнеш һәм милли колоритны кvреп ала: «Без жәйге ярышларны Чирмеш авылындагы «Эндуро» уздырдык инде. Биредә ярышлар vткәрv очен яхшы урын: таулар, биеклекнен кискен менv-тошv табигый киртәләр. Гугл-карталардан якындагы урманнын «Кузямбай» дип аталуы ачыкланды. Исем безгә бик ошады һәм безнен ярышларнын рәсми атамасы да итеп алынды. «Кышкы Кузямбай - 2025» ярышы чын бәйрәмгә әверелде һәм дистәләгән тамашачыны жыйды», - дигән ярышны оештыручы һәм катнашучысы Александр Морозов.
Салкын да, кискен жил дә комачауламаган ярышучыларга. Кар трассасы янына Чирмеш, Ләмберә, Саранск һәм башка авыллардан халык кvп иттереп жыелган. Трасса, сvз унаеннан, Ләмберә техникасы белән чистартылган. Район администрациясе Саранск мотоклубын хуплап, бәйрәм унышлы узсын очен, барысын да эшләгән. Ярышнын музыкаль олешен «Алмаз» мәдәни-спорт vзәгенен кvчмә клубы тәэмин иткән һәм ижади номерларны Александровка һәм Пензятка авыл клубларынын талантлы солистлары тәкъдим итте.
Мотоспорт бәйрәмендә теләгән һәркем катнашкан. Спортчылар мотоцикллар, сноубайкалар, квадроцикллар һәм снегоходлар кебек техника торләре буенча торкемнәргә бvленгәннәр. Ярыш узышлары табигый рельефлы - таучыклар, тигезсезлекләр, киртәләр арасында барды. Барлыгы биш дисциплина буенча 50 кеше катнашты. Жинvчеләр арасында Чирмеш авылыннан ике катнашучы жинvчеләр рәтендә. «Мотокросс – класс открытый без шипов» номинациясендә беренче урынны Рушан Яфуняев алган, ә икенче урынны Риан Солдатов яулаган.
«Жәйге Кузямбай» да булыр, кунакчыл Ләмберә жирендә тагын берничә тапкыр очрашырбыз дип ометләбез.
Искәрмә. «Эндуро» инглиз телендә indurare - чыдарга, тvзәргә дигәнне анлата. Бу ярышларнын катлаулылыгына карап, юлсыз, таш кыялар һәм башка киртәләр белән тутырылган махсуслаштырылган спорт трассаларында йорvнен агрессив стилен кvздә тота. Бу дисциплина очен тиешле спорт мотоциклы (велосипед) техникасын кулланалар. Хәрәкәтнен даимилегенә ярышлардан тыш, эндурога кыска вакыт эчендә остәмә ярышларнын шартларын vтәv дә кертелгән.

Наилә НАСЫРОВА